


ФИРАЯ ХӘЛИУЛЛИНА

ЧАЛЛЫ КИЛӘ

Чаллы урамында якты көннәр...
Яңа гына шытып килә үлән.
Яз иңенә басып бер пар килә
Башланмаган яңа тормыш белән.

Кызның кулларында кызыл гөлләр,
Ак күлмәген сирпеп исә җилләр;
Йөзләрендә кояш елмаюы,
Мин бәхетле диләр гүя күзләр.

Ташчы кыз ул — шәһәр яхшы белә,
Һәркемгә дә якын эше белән.
Кулы тисә, шәһәр калкып чыга,
Гөлләр шыта саф сулышы белән.

Күр син, ничек кыю атлап килә,
Бәхете булыр ди гөлләр гүя;
Чөнки атлый бергә чор язмышы,
Чаллы атлый зур җиңүләр белән.

Ә мин шушы сылу язмышында
Шәһәр, авыл язмышларын күрәм;
Чаллы да бит ак күлмәктән бүген
Ак чорларга кыю атлап керә.

**Фирая Хәлиуллина**

**Чаллы килә**

Чаллы урамында якты көннәр...

Яңа гына шытып килә үлән.

Яз иңенә басып бер пар килә

Башланмаган яңа тормыш белән.

Кызның кулларында кызыл гөлләр,

Ак күлмәген сирпеп исә җилләр;

Йөзләрендә кояш елмаюы,

Мин бәхетле диләр гүя күзләр.

Ташчы кыз ул- шәһәр яхшы белә,

Һәркемгә дә якын эше белән.

Кулы тисә, шәһәр калкып чыга,

Гөлләр шыта саф сулышы белән.

Күр син, ничек кыю атлап килә,

Бәхете булыр ди гөлләр гүя;

Чөнки атлый бергә чор язмышшы,

Чаллы атлый зур җиңүләр белән.

Ә мин шушы сылу язмышымда

Шәһәр, авыл язмышларын күрәм;

Чаллы да бит ак күлмәктән бүген

Ак чорларга кыю атлап керә.